# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге составынакерүче Ташлы авылында үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

№ 9 «29» октябрь, 2025 ел

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 нче статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ санлы Татарстан Республикасы законының 35 нчестатьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге муниципаль берәмлеге» Уставының 23 статьясы, Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлегенең Ташлы авыллары авылында 2025 елның «29» октябрендә узганү зарасалым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлегенең Ташлы авыллары авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, 1,2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары, сугыш хәрәкәтләре ветераннары, күп балалы гаиләләрдән, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары кала, 2026 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

-торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту: (урам юлларын кардан чистарту һәм юлларны тигезләү);

-электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар янындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм башка билгеләнгән җайланмаларны ремонтлау: (агымдагы ремонт, урам утлары лампаларын сатып алу һәм алыштыру):

« ӘЙЕ » « ЮК »

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 25 кешекертелгән;

гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны: 20 кеше, 80% тәшкил итә:

Гражданнар җыенында катнашучыларның ачык тавыш бирү нәтиҗәләре түбәндәгечәбүленде:
«РИЗА» позициясеөчен 20 граждан тавыш бирде;
«КАРШЫ»позициясеөчен 0 граждан тавыш бирде;

Бәянителгәннәрнигезендә, халык җыены КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1.Гражданнарның үзарасалымакчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлегенең Ташлы авыллары авылында узган гражданнар җыенын - уздырылган, нәтиҗәләре - дөрес, дип танырга.

2. Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлегенең Ташлы авыллары авылында түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыены карарын кабул ителгән дип танырга: «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлегенең Ташлы авыллары авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, 1,2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераннары, сугыш хәрәкәтләре ветераннары, күп балалы гаиләләрдән, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзалары кала, 2026 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

-торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту: (урам юлларын кардан чистарту һәм юлларны тигезләү);

-электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар янындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм башка билгеләнгән җайланмаларны ремонтлау: (агымдагы ремонт, урам утлары лампаларын сатып алу һәм алыштыру).

3. Әлеге карарны Кызыл Тау авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Кызыл Тау авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актларыРегистрына кертү өченҗибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Мамадыш муниципаль районы
Кызыл Тау авыл җирлеге Башлыгы,
Совет рәисе В.А.Гиззатуллина